**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ПУЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423730, Пучы авылы, Киров урамы, 1 нче йорт. Тел.3-44-51.

**СОВЕТ ПОИСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** 423730,село Поисево, улица Кирова,дом 1.

Тел. 3-44-51.

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР
№ 3　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　от 26.02.2021г.

**Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының 07.09.2017ел, № 20 «Пучы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге Советының 07.09.2017ел, № 20 «Пучы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Пучы җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Пучы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Пучы авыл җирлеге
Советы Башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　Н.З. Нуртдинов